СОВЕТ
ЯНГА - САЛСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.18, с. Янга-Сала,
Арский муниципальный район, 422011

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢАСАЛА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 18 йорт, Яңасала авылы,
Арча муниципаль районы, 422011

Тел. (84366) 57-2-10, факс (84366) 57-2-10. E-mail: Yns.Ars@tatar.ru www.arsk.tatarstan.ru

**Яңасала авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**30 сентябрь 2016 ел** **№ 21**

**Референдум уздыру буенча инициатива күрсәтү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Җирле референдум уздыруны түбәндәге сорау буенча тәкъдим итәргә:

«2017 елда Яңасала авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә (түләү күләме 250 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, 70 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш,) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар | тоту өчен акча күләме /сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге | - Яңасала авыл җирлеге составына керүче юлларга вак таш җәю:<br>Яңа Сала авылы, Яшьләр ур., 1 -9;<br>Каенсар авылы, Урта ур., 1-26 | 91200 |
| | | | 91200 |

әйе юк

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә гражданнар күпләп җыела торган урыннарда

түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Арча районы, Яңасала авылы, Үзәк ур., 20 йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Каенсар авылы, Урта ур., 25 йорт.

Яңасала авыл җирлеге башлыгы А.И. Сафин

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ЯНГА-САЛСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
СОВЕТ
ЯНГА-САЛСКОГО
СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1609003024